





# Салавыз - Мухан мәктәбе тарихы



1907 - -2020

## Беренче мәктәпләр

Авылда XX гасыр башында бернинди дә аң - белем учагы булмый. Фәкать Кашап һәм Кәлимулла хәзрәтләр генә белемле кеше булганнар.

1907 нче елда Кәлимулла хәзрәт татар балалары өчен мәдрәсә ачкан һәм ир балаларга дин сабагы укыткан.

1910 елда Сөләйманов Кашап хәзрәт, Гыйлфанов Кирам исемле кеше өендә, кыз балаларны укыту өчен мәктәп оештыра. Монда Сөләйманова Фәрхинур абыстай укыткан. Берничә айдан соң Сара исемле мөгаллимә килә.

1911 елда Кашап хәзрәт инициативасы һәм халык ярдәме белән мәктәп өчен яңа бина салына. Ул алты почмаклы йорттан тора. Шәкертләргә юыну, ашарга пешерү урыннары булдырыла. Урын - җир сәндерәгә урнашкан була. 1912 нче елда укучылар өчен кечкенә кара такта, бераз грифельләр, әзрәк дәреслекләр дә юнәткәннәр. Шушы ук елны Хаҗәр исемле яңа мөгаллимә укытырга килә. Ул килгәч, хисап, география, тарих укытыла башлый. Элеккечә үк Фәрхинур абыстай дин сабагы укытуын дәвам итә.

Мәдрәсәнең даны тирә - юньгә тарала. Анда укырга күрше авыллардан да кызлар килә. Укучылар, өч елдан соң имтихан биреп, мәдрәсәне тәмамлаганнар.



Рәсемдә: Сөләйманов Кашап ачкан мәктәпне тәмамлап, дәреслекләр язу дәрәҗәсенә күтәрелгән Мәрьям Шакир кызы Галләмова.

**Яңа мәктәп ачылу һәм яңача яңача укыта башлау**

1928 елда балаларны яңача укыту оештырыла. Мәктәп Кирам карт өендә була. Төрле яшьтәге балалар бергә укый. Соңыннан Әхмәтвәли өендә укыганнар. Анда сыймаганнары Шияп Сәхәпов өендә укыганнар. Аларны Уразов укыткан.

1928 - 1934 нче елларда I - IV класслар булган. 1930 елда таштан мәктәп салынган, класслар саны арткан. Укучыларга Галиев Нурлыгаян белем бирә башлый. Фотода ул уңнан беренче.

1937 елда авылда тулы булмаган урта мәктәп ачыла. Монда Салавыз-Мухан һәм Иске Чакмак авылы балалары белем алалар.





1941 нче елда Бөек Ватан сугышы башлана.

Сугыш! Бу сүзне әйткәч тә күңелләр өшеп китә. Күпме афәт, күпме михнәт, күз яшьләре!

Салавыз – Мухан авылын да читләтеп үтмәгән бу сугыш. Сөлектәй таза 167 ир - егетне аналары, хатыннары, сөйгән ярлары авыр сугышка озатып кала. Гаиләләреннән өч, дүрт, бишәр баласын озатканнарны хәтерли бүген авыл кешеләре. Менә алар: Валиевлар – 4, Галиевлар – 4, Локмановлар - 4,

берсе исән, Нуриевлар – 5, берсе генә исән кайткан. 1418 көнгә сузылган бу сугышта авылның 106 кешесе сугыш кырларында ятып кала, шулар арасында хәбәрсез югалганнары да бик күп. Бары 61 енә генә исән – имин көе туган якларына кире әйләнеп кайтырга насыйп була.

Авылдан Бөек Ватан сугышында 5 укытучы да катнаша: Апукаев Әзһәр Абдулла улы, Галиев Нурлыгаян Габдерәхим улы, Сөләйманов Мисбах Кашап улы, Әхмәтов Сәетнәсим Вагыйз улы, Фатхуллов Мирсәет. Алдагы язмада аларнын өчесе белән якыннан танышып китәрбез.



**Сөләйманов Мисбах Кашап улы** 1912 елның 12 гыйнварында Мөслим районының Салавыз - Мухан авылында Кашап хәзрәт гаиләсендә 6 нчы бала булып дөньяга килә. Әтисе, авылның мулласы булса да, гади крестьян тормышы белән яши. Кашап Сөләйман улы бик укымышлы була.

Мисбах абый, авыл мәктәбен тәмамлагач, Минзәлә җидееллык мәктәбенә укырга керә. Бик шук егет булса да, мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлый.

1930 - 1933 елда Казан силикат техникумында белем ала һәм укуын тәмамлагач, 1 май исемендәге силикат заводына техник - технолог булып эшкә урнаша.

1935 елда Казан дәүләт университетының физика - математика факультетына укырга керә, ләкин аңа укуын тәмамларга насыйп булмый. 1937 елның ноябрь аенда Мисбах абыйны кулга алалар. Аңа РСФСР ның УК 58 нче статьясының 7, 10, 14 нче пунктлары буенча (вредительство, контрреволюционая агитация, организация группы) яла ягыла һәм поезд белән Ташкент төрмәсенә җибәрелә, ә аннан соң тоткыннарны Сызраньга озаталар. Егет үзененең яшь гомерен төрмәдә уздыруын куз алдына да китерә алмый.

Мисбах абый төрмәдә Морзе әлифбасына өйрәнә, үзе дә сизмәстән, радист - телеграфист һөнәрен үзләштерә. Ниһаять, 1939 елның 24 январендә, ТАССР ның Югары суды карары нигезендә, Сөләйманов Мисбах Кашаповичның гаебе юклыгы раслана, ул иреккә чыгарыла.

Төрмәдән чыкач, ул рус теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү курсларын тәмамлап, Мөслим районының Кубәк урта мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнә.



1942 нче елның 24 мартында Мисбах абый сугышка китә, радист - телеграфист булып, көньяк фронтка эләгә.

1945 нче елның 12 октябрендә демобилизацияләнеп Казанга кайта. 9 ай буе Казанда “Волгопром” заводында эшли



Укытучы булу теләге көчле була һәм бу теләк аны яңадан туган якларына кайтара. Ниһаять, 1946 – 47 нче уку елында, туган авылы Салавыз – Муханда, рус теле һәм әдәбияты укытучысы, завуч булып эшли башлый. Күрше авыл кызы Фәкыя белән тормыш коралар: 2 уллары һәм 3 кызлары туа.

Балалары өчен Мисбах Кашапович гадел һәм тәлапчән әти булса, тормыш иптәше Фәкыя Гиздулловна өчен зур терәк, киңәшче була.



Мисбах Кашапович җаны - тәне белән укучыларына ныклы белем бирергә омтыла һәм аларны тәрбияләүне дә узенең бурычы дип саный.

Укучылар белән берлектә авыл тирәсен яшелләндерүдә дә зур көч куялар: Түтәләм чокыры тирәсен чүптән арындыралар, тирә – юне ишелеп төшмәсен өчен агачлар

утырталар. хәзерге яшелчә бакчасында да агачлар утыртуда актив катнашалар. Шушы эшләрне башкарган өчен Мисбах абый, совхоздан акча һәм машина сорап алып, укучыларны Татарстан шәһәрләре, нефть чыгу урыннары, КамАЗ һәм Түбән Кама заводларының нигезе салынган урыннарга сәяхәткә алып бара.



Укучылыры да Мисбах абыйларын онытмадылар. Ялга кайткач, аның янына кереп, хәлен белеп, узләренең рәхмәтләрен әйтеп чыга иделәр. Мисбах абый өчен бу рәхмәтләр дәүләт буләкләреннән кадерлерәк иде...

Сөләйманов Мисбах Кашапович 40 елдан артык гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлады. Татар укытучылырның 3 нче съездында делегат булып катнашты. Мәгариф отличнигы исеменә лаек булды.

**Галиев Нурлыгаян Гәбдерәхим улы** 1906 нчы елның 25 августында, Салауз - Мухан авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Мәдрәсәдә белем ала, аннан Минзәләдә укый. Партиягә керә, партия хезмәткәре булып эшли.

1930 елда Кашап кызы Мәхтүмәгә өйләнә. Шул ук елны Салавыз - Мухан мәктәбендә укыта башлый.

1941 елны, Бөек Ватан сугышы башлангач, ул хатыны Мәхтүмәне өч баласы белән калдырып, фронтка китә. Фронт белән ике арада хатлар йөри башлый. 1942 нче елның 5 ноябрендә аның соңгы хаты килә. 1943 нче елның январендә “Хәбәрсез югалды” дигән хат килә. Ана карынында калган улы Фоат 1942 нче елда туа. “Әти” сүзен бер әйтергә тилмереп үскән буын без,”- дип уфтана ул.



Фотода Галиев Нурлыгаян узенен туганы Мәрьям Шакир кызы Гәлләмова белән.

Тагын бер фронтовик укытучыбыз – Апукаев Әзһәр Абдулла улы. Без аның белән дә хаклы рәвештә горурланабыз.

**Апукаев Әзһәр Абдулла улы** 1918 елда Мөслим районы Вәрәшбаш авылында туа. Әтисе бик оста тегүче була. Бибисара белән икесенә өч ул, ике кыз тәрбияли алар.



Әзһәр мәктәпне тәмамлаганнан соң, Минзәлә училищесына укырга керә.

1940 елдан армия хезмәтенә чакырылып, Бөек Ватан сугышының беренче көненнән Җиңү көненә кадәр сугышта катнашкан, аннан соң 1946 елның көзенә кадәр армия сафларында хезмәткә калдырылган, ил чикләрен, аның азатлыгын саклауга җиде ел гомерен биргән Әзһәр Апукаевның күкрәген Кызыл Йолдыз һәм I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, Германияне җиңгән, Вена, Будапешт, Белградны азат иткән өчен бирелгән медальләр бизи. Туры сүзле, гадел һәм тыйнак, Халык мәгарифе отличнигы Әзһәр абый сөйләшергә - гәпләшергә дәрт кеше булса

да, сугышта күргәннәрен, андагы мәхшәрне сөйләргә, орден - медальләрен тагып йөрергә яратмый иде. Кеше буларак дөрес тәрбия алган бу ветеран халык өчен, дәүләтебез өчен бөтен тырышлыгын биргән, әмма үзе өчен бер нәрсә таләп итмәгән, хезмәт көченә таянып яшәгән, саф күңелле кеше була.

Сугышка Апукаевлар гаиләсеннән тетрәп торган 4 ир - егет чыгып китә. Өч малае: Әнвәр, Әзһәр, Сәгыйрь белән бергә ире Абдулланы да озата әниләре. Әнвәрбәктән кала башкалары исән кайта.

1948 - 1961 елларда колхоз партком секретаре, 20 авылда җәмәгать суды рәисе булып эшли. 1955 - 1959 елларда Октябрь мәктәбендә укыта. Салавыз - Мухан 8 еллык мәктәбе директоры булып эшләгәндә интернат бинасын салдыра. Мәктәп музеена нигез сала, аңа материаллар туплый...

Әзһәр Абдуллович гомеренең соңгы көненә кадәр мәктәп яңалыклары белән кызыксынып яшәде, үзенең киңәшләре белән ярдәм итеп торды. 2007 елны вафат булды.

**Тулы булмаган урта мәктәп**




*1965 нче елда салынган яңа мәктәп бинасы*

1962 елда җидееллык мәктәп сигезьеллык итеп үзгәртелә. Бу елларда укыткан укытучылар: Сафина Банат, Хафизова Нәгыймә, Бәдертдинова Кәнҗелбанат, Шәяхмәтова Разия, Апукаев Әзһәр Абдуллович, Ганиева

Нәгыймә Зиятдиновна, Сөләйманов Мисбах Кашапович, Сөләйманова Фәкыя Гыйздулловна, Егорова Галина Романовна, Әюпов Миргалим Әюпович, Зарипова Сәһимә, Вәлиева Җинан Вәлиевна, Ибраһимова Рәйсә Кариевна.

1963 елда мәктәпкә директор булып Хаҗиев Равил килә. Иптәше Галиева Нурия биология фәнен укыта. Хаҗиев Равил житәкчелегендә 1965 елда яңа мәктәп салына.

50 нче елларда мәктәптә 100 – 152, 1955 - 1960 нчы елларда 75 - 80 укучы  була. 1970 - 1980 нче елларда укучылар саны арта барып 1971 - 1972 нче уку елында 198 гә җитә.

1988 нче елнын февралендә яңа типтагы мәктәпнен нигезе салына



башлый. 1989 нчы елның 4 нче ноябрендә 192 урынга исәпләнгән мәктәп бинасы файдалануга тапшырыла. Аны төзүдә 17 ел мәктәп директоры булып эшләгән Хәйдәров Миргазыян Хәйдәр улынын хезмәте зур.

1991 нче елның 30 нчы августында “Авыл утлары” газетасында басылып чыккан “Олы җанлы кеше” дигән мәкаләдән өзек:

“...Соңгы звонок шалтырап, кемнәрнедер олы юлга, кемнәрнедер озын каникулга чыгаруга шактый вакыт узды. Яраткан мәктәпкә, яраткан укытучылар янына килү көне якынайды. Чынлап та, яраткан укытучылар күп бит алар. Җаны –тәне белән белем һәм тәрбия бирергә, олы киңәшчең, юл

күрсәтүчең булырга әзер кешене ничек якын итмисең дә, ничек сагынмыйсың?



Салавыз - Мухан урта мәктәбенең тарих-география укытучысы, халык мәгарифе отличнигы Хәйдәров Миргазиян Хәйдәрович олы ихтирамга һәм хөрмәткә лаек педагогларның берсе. Аның төгәллеге, фикеренең нык һәм төпле булуына, үз эшенә бирелгән булуына без - районның тарих укытучылары һәрчак сокланабыз. Ул һәрвакыт ачык йоз белән каршы ала. Кабинеты җиренә җиткереп җиһазланган, кирәкле күргәзмә әсбаплар һәм өстәмә әдәбият кул астында. Чисталык, тәртип, гөлләр.- көннең буе биредә булсаң да ялыкмассың, бөтенесе үзенә тартып тора. Музей - район мәктәпләрендә иң аксаган урын, ә биредә ул беренче планда. Авылның үткәне, бүгенгесе, табигате, совхоз уңганнары, әфган сугышы батырлары, мәктәп тарихы - барысы да игътибар үзәгендә. Ул әзерләгән экскурсоводлар татар милли киемнәреннән була, һәрберсе оста итеп чыгыш ясарга өйрәнгән. Укытучы фотога оста төшерә, музей мәктәпнең һәм совхозның бүгенгесен сурәтләгән фотокарточкалар белән баетыла.

Миргазиян Хәйдәрович – иң беренче чиратта оста педагог, аның дәресләре бөтен таләпләргә дә җавап бирә. Укытучы һәм укучылар дәрес буе эшлиләр, эзләнәләр. Катлаулы гына темалар да иң аңлаешлы юл белән җиткерелә. Дәрестә күргәзмәлелек көчле, магнитофон һәм музыка күп файдаланыла. Без, тарих укытучылары, ничә еллар инде коллегабызның дәресләрендә булабыз. Аларда һәрвакыт – ниндидер яңалык, тормыш үзе.

Озак еллар аның шушы мәктәптә директор булып эшләве, бүгенге көндә үзенә таяныч булуы турында горурланып сөйли яңа директор Марс Тимергалиев.

Коллективның дус, эшчән, тату, кунакчыл булуы беренче карашка ук күзгә ташлана. Миргазиян Хәйдәровичны ТАССР мәктәпләренең атказанган укытучысы исеменә тәкъдим иткәннәр. Олы җанлы, тырыш, өлкән педагогка күрсәтелгән әлеге хөрмәткә районның тарих укытучылары да кушыла. Эшендә уңышлар, сәламәтлек телибез, матур дәресләре белән безне күп

мәртәбәләр куандырыр дип уйлыйбыз,”- дип яза тарих укытучыларының район методик берләшмәсе җитәкчесе Талыйпова Ләлә Әсхәтовна.



1991 - 1992 нче уку елында, ата-аналар соравы һәм Тимергалиев Марс Мөдәссир улы инициативасы белән, Салавыз - Мухан сигезьеллык мәктәбе зур үзгәреш кичерә: Мәгариф министры Гайфуллин Васил Габдулла улы приказы нигезендә сигезьеллык мәктәп урта мәктәп итеп узгәртелә. Ул бүләк итеп 20 мең сум акча бирә. Бу сумма мәктәпне җиһазлау өчен тотыла. “Үзәк” совхозы директоры Мәгалимов Габдулла Фәрди улы, партком секретаре Ханнанов Миргарифан Мирзагали улы, авыл советы председателе Саматова Мәгъфүрә Акмал кызы, РОНО мөдире Йосыпов Мәрәк Шәйхерахман улының өлеше дә зур була.

2006 нчы елда укучылар саны кимү сәбәпле, мәктәп төп гомуми белем бирү мәктәбе итеп узгәртелә.



Мәктәбебезнең иң өлкән, зур хөрмәткә лаек ветеран укытучыбыз **– Вәлиева Җинан Вәли кызы** 1917 нче елның 10 нчы октябрендә Салавыз - Мухан авылында ярлы крестьян Вәли абзый белән Дөрлеҗинан апалар гаиләсендә дөньяга аваз сала.

1928 нче елда, авылда башлангыч мәктәп ачылгач, ул 1 нче класска укырга керә. "Без төрле яшьтәге балалар бергә утырып укый идек", - дип искә ала Җинан апа.

Алга таба белем алуга теләге булган кызны 1932 нче елда Мөслим урта мәктәбенә укырга илтәләр. "Ат чанасына утырып укырга йөри идек", - дип искә ала Җинан апа.

Мөслим урта мәктәбен уңышлы тәмамлаганнан соң, кызның алга таба өметле икәнен күреп, укытучылары аңа Минзәлә педагогия училищесына барырга киңәш итәләр. 1936 нчы ел – кыз өчен киләчәген хәл итүче ел була. Минзәләдә укытучылар хәзерли торган училищеда укый башлый. Аны яхшы билгеләргә тәмамлап, 1937 нче елда Калинин районы Иске Сәфәр авылында укытучы булып хезмәт юлын башлап җибәрә. Бу хезмәтне ул Чуракай, Тойгелде, Вәрәшбаш авылында дәвам итә.

1942 нче елда туган авылы Салавыз – Муханда татар теле һәм математика фәннәрен укыта башлый. Җинан апаның беренче укучылары Хабирова Сәлимә, Гарифуллина Мөгаллимә, Исламова Мөгаллимә.


Авыр сугыш елларында ул укытучы гына түгел, бөтен аналарның да олы киңәшчесе, терәге була. "Ул еллардагы авырлыкны сөйләп кенә аңлатып булмый. Класслар суык, ягарга утын юк. Балаларның өс - башлары юк. Без - укытучылар балаларның кайберләрен күтәреп алып килеп, кире илтеп куя идек, өйләренә барып укыта идек. язарга кәгазь, кара юк, тапкан очракта да диктант, контроль эшләр өчен генә таба идек. Балалар мәктәпкә килгәнче аръякка камыш, тал җыярга чыгалар. Озын тәнәфестә өйләренә кайтып ашап киләләр иде. Авыр булса да тырышып укыдылар, китапларны күз карасыдай сакладылар. Ул чорда без "Син фронт өчен нәрсә эшләдең?" лозунгы астында эшләдек. Дәрестән соң укучылар белән кешеләрдән җылы киемнәр

җыеп фронтка җибәрә идек.  Көлтә ташыдык, атлар белән сабан да сөрдек”, - дип искә ала Җинан апа.

1942 - 1943 нче елларда мәктәп директоры  вазыйфасын намус белән үти. 1943 нче елда бөтен авылда ангина чире башлана. Мәктәпең 2 классын бушатып больница ачалар. Мәктәп ул чорда 2 сменага күчә. Укытучыларга үзләренә медсестра булырга туры килә. “Ничек кенә тырышсак та, 50 гә якын кеше үлде. Шушы авыр чорда да төшенкелеккә бирелмәдек, җаныбыз - тәнебез белән тырыштык,”- дип искә ала укытучы.

Валиева Гайнелҗинан 1944 нче елда коммунистлар сафына кабул ителә. Үзе өчен иң кадерле булган партия билетын мәктәп музеенда сакланыр дип безгә бирде.

1946 нчы елда Җинан апа авылдашы Гизетдинов Фатыйх белән тормыш кора. Дөньяга бер – бер артлы кызлары, уллары туа: Зөһрә, Фирдәвес, Наил, Райхан. Җинан апа яхшы ана, тормыш иптәше Фатыйх абыйга ышанычлы терәк була. Фатыйх абый ферма мөдире, авыл советы председателе, 7 ел колхоз председателе булып эшли. Ни кадәр тынгысыз хезмәт, йокысыз төннәрне бергә бүлешәләр алар. Ләкин тормыш йөген пар канат белән бергә тартырга насыйп булмый аларга. Фатыйх абый яшьли гүр иясе була. Балаларны үстереп, укытып, яраткан хезмәтен җиренә җиткереп башкарасы бар. Сабыр холыклы Җинан апа сынмый, сыгылмый, 1972  нче  елга кадәр туган мәктәбендә, пенсиягә чыкканчы эшли. Ул үзенең намуслы, фидакарь хезмәтен - 36 ел гомерен балаларга багышлый. Җинан апаның изгелекләрен укучылары хәзердә онытмыйлар. Һәрвакыт аны зур хөрмәт белән искә алалар.



Рәсемдә:

Җинан апа үзенең хезмәттәшләре Бәдретдинова Кәнҗелбанат, Ганиева Нәгыймә белән, 1971 нче ел.

**Бәдертдинова Кәнҗелбанат Бәдретдин кызы**

1918 нче елның 3 нче февралендә Салавыз - Мухан авылында туа. 1928 нче елны 1 нче класска укырга керә.



Алар башта үз авылларында Вәли бай дигән кешенең өендә укыганнар. 1932 нче елның беренче сентябрендә Мөслимгә бишенче класска укырга килгәннәр. Сигезенче классны Мөслимдә тәмамлыйлар һәм төрлесе төрле якка таралалар. 1936-1937 нче уку елында тугызынчы класска бары тик җиде укучы укырга кала. Шулар арасыннан Мухан авылыннан бердән - бер укучы Банат апа була. Мөслим урта мәктәбен бу җиде укучы 1938 нче елны тәмамлый. Банат апа Мөслим районының Олы Чакмак, Метрәй, Тат.Смыловка, Сал. Мухан, Симәк авылларында укыткан.

Халыкта бер сүз бар: изгелек эшлә дә җиргә сип. Ул орлык булып күп шытымнар бирә. Кешенең кылган эшләре исә җирдә кала, кешеләргә кала. Банат апаның кылган изге гамәлләре, эшләре дә шулай: укучылары күңелендә, туганнары йөрәгендә яши.



Арткы рәт, сулдан уңга: А. Ләис, Сәләхетдин, Х. Гөлсинә, Б. Банат апа, М.Тәнзилә, Г.Фоат, М.Нуриасма.

Аскы рәт, сулдан уңга: Җ.Фоат, Мулланур, Ш.Каюм, Ә.Рим, Г.Тәслимә, Х.Гаишә, Наимә.

**Гыйздуллина (Сөләйманова) Факыя Гыйздулловна**



Гыйздуллина (Сөләйманова) Факыя Гыйздулловна 1922 елның 5 нче октябрендә Мөслим районының Метрәй авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган.

1937 нче елны 7 нче классны “5” ле билгеләренә генә тәмамлап, Минзәлә педагогия училещесына укырга керә. 1937 нче елны комсомолга керә,зур дәрт белән җәмәгать эшләрендә катнаша.

1939 нчы ел - Финляндия сугышы вакыты. Укытучылар җитмәү сәбәпле, студентларны укытырга җибәрәләр. Фәкыя апа Калинин (хәзерге Актаныш) районына эләгә. 1 нче сентябрьдән Куҗәкә җидееллык мәктәбендә укыта башлый.1940 нчы елның 9 нчы октябреннән Калинин районы Байсар урта мәктәбендә укыта. Байсарда эшләгәндә комсомол оешмасының секретаре булып эшли.

1941 нче елның 22 нче июнендә сугыш башлана. Ир - егетләр сугышка китә. Бөтен авырлык хатын - кызлар, бала - чага һәм карт - корылар өстенә кала.

Фәкыя апа ул көннәрне болай дип искә ала: ”Иртән укытырга бардым, аннан балалар белән башак җыярга, носилка белән көлтә ташырга китә идек. Балаларны кайтаргач, комсомоллар белән төнге сменага көлтә ташырга китә идек. Сугыш елларында без яшьләр белән бик күп эшләр эшләдек. Ашлык амбарлары, ат-сыер тораклары янындагы каравылларны тикшердек, стена газеталары, ”Сугышчан листок” чыгардык, походлар оештырдык.

Сугыш еллары бик авыр булды. Эшләгән балаларга он бирәләр иде, ул онны кашыклап бүлеп калганнын чеметеп бүлә идек.

Ай, ул елларның авырлыгы! Шулай да, балалар төшенкелеккә бирелмәделәр.”4” һәм “5”ле билгеләренә генә укыдылар. Язарга кәгазь юк, китап битләренә яздылар. Кара - алар өчен корым. Ашарга җитми, өс - башка юк. Әле дә түздек, булганны фронтка җибәрергә тырыштык”

1943 нче елны Фәкыя апаны Байсар мәктәбеннән Калинин районы РДТС ка директор итеп күчерәләр.

1951 нче елның 27 сентяберендә Сөләйманова Фәкыя Гиздулловна "За трудовое отличие" медале белән бүләкләнә .

1956 нчы елны Татарстан укытучыларының 2 нче съездында катнаша.

Югары белем алу максаты белән, 1960 нчы елны Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга китә. 1964 нче елны Фәкыя апа институтны тәмамлый, татар теле һәм әдәбият дәресләрен Мухан мәктәбендә яратып, җанын - тәнен биреп укыта.

1965 нче елда Салавыз-Мухан мәктәбенең директоры итеп билгеләнә. 1971 нче елга кадәр директор була, аннан завуч булып эшли.

1972 нче елда лаеклы ялга чыга. Гомеренен соңгы көннәренә кадәр мәктәп белән тыгыз элемтәдә яшәде.

**Ганиева Нәгыймә Зыятдин кызы**



Ганиева Нәгыймә Зыятдин кызы 1927 елның 7 нче мартында Вәрәшбаш авылында туа. Гаиләдә 5 бала арасында 4 нче кыз булып дөньяга килә.

7 нче классны бетергәч сугыш вакытында, калхозда эшлиләр. Ашлык сугалар, фронтка биялэй, оекбашлар, кулъяулыклар һәм ашамлыклар пешереп җибәрәләр. Ул пионер, камсомол оешмалары оештыру эшләрен укытучыга йөкләгән классlар белән авылларга концерт куярга барганннар. Әтисе Ганиев Зыятдин, әнисе Ганиева Зәйтунә (кыз фамилиясе - Мифтахова). Әтисе гади калхозчы, башта авыл советы председателе, Мөслимдә банкта эшләгән. Ә әнисе Мөслимдә колхозда эшләгән. 2 абыйсы да сугышта булган. Берсе кайткан. Бер апасы Метрәйдә укытучы булган. Апсы һәм бер абыйсы вафат була

Җидееллык мәктәпне тәмамлап, Мөслим урта мәктәбенә белем алырга укырга китә. Укытучылар курсларына 10 айга укырга җибәрәләр. Ул физика -

математика укытучысы дигән белгечлеккә ия була. Диплом алып, 1945 нче елларда Салавыз - Мухан мәктәбендә физика - математика укытучасы булып эшкә килә. 1948 нче елда Әзһәр абыйга кияүгә чыга, бер – бер артлы 3 бала: 1 малай, 2 кыз дөньяга килә.

Нәгыймә апа, 17 ел дәвамында югары классларда белем һәм тәрбия бирә, аннан соң, лаеклы ялга чыкканчы башлангыч классларда укыта. Хезмәттәшләре аны нечкә куңелле, сабыр, тыйнак кеше буларак искә алалар. Халык мәгарифы отличнигы дигән мактаулы исемгә лаек була һәм медаль белән бүләкләнә.



Рәсемдә: Укытучылар коллективы. Икенче рәттә, сулгдан беренче Нәгыймә апа Ганиева

**Габдуллина Сәвия Габдулла кызы истәлекләреннән:**



Мин 1954 нче елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамладым. Ул елларда, укып бетергәннән соң, училищедан юллама бирмиләр иде, чөнки мәктәпләрдә балалар саны аз, эш юк, күпләп укытучыларны кыскарталар иде,"- дип искә ала Сәвия апа.

Габдуллина Сәвия апа хезмәт юлын, 1954 нче елда, Баек җидееллык мәктәбендә башлый. Анда ул декрет ялына чыгучы Шакирова Наилә урынына укыта. Шул ук елны Салавыз - Мухан мәктәбенә күчерелә һәм ул беренче класс укучыларын укыта башлый.

Сәвия төрле фәннәрне дә укыта алырлык укытучы булып җитешә. Салавыз - Мухан җидееллык, сигезеллык мәктәпләрендә җыр, математика, татар теле һәм әдәбияты, биология фәннәрен укыта. Биология фәнен укытканда Татарстан мәгариф министрының Мактау грамотасы белән бүләкләнә, завуч, озынайтылган көн группасында һәм интернатта тәрбияче булып эшли.



Рәсемдә: Сәвия Габдулла кызы үзенен беренче класс укучылары белән: Кирамова (Биккинина) Рәйсә, Гафарова Фаягөл, Сәетова Зөлфия, Миргасимова Флера, Хасанов Рафик, Шәвәлиева Флера, Хәлимова Зөлфинә, Вәлиева Хафиза, Хәлимов Гаяз, Сәгъдиева Гөлсинә, Гизетдинов Нәҗметдин, Латипова Гайшә, Шәяхметов Мулланур. 1955 нче ел.

Салавыз - Мухан мәктәбендә эшләгән елларын искә алганда Сәвия апа: “Һәрвакыт дус, тату коллектив булып эшләдек. Бергә эшләгән хезмәттәшләрем: Вәлиева Җинан, Сөләйманов Мисбах, Фәкыя, Апукаев Әзһәр, Ганиева Нәгыймә, Ибраһимова Рәйсә,Нуриев Миргалим,Әюпов Миргалим, Бәдретдинова Банат, Хәйдәровлар. Аларна һәрвакыт сагынып искә алам”,- ди.

Сәвия Габдулла кызы җырларга, мандолинада уйнарга ярата, сәнгатькә гашыйк кеше була. “Авылда үткәрелгән чаралар, спектакльләр аннан башка үтми иде”, -дип искә ала өлкәннәр. Уйнаган рольләрен авыл халкы хәзер дә яратып сөйли, искә ала.



*Рәсемдә: Ганиева Нәгыймә, Габдуллина Сәвия, Ханнанов Миргарифан,Тимергалиев Марс.*

Габдуллина Сәвия Габдулла кызы 1987 нче елда лаеклы ялга чыга. Ялга чыкканда зур бүләк - мәгариф министрының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.